ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

КАРАР

1 ноябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2022 елның 15 нче ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенынын үткәрү вакыты – 15 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Кызыл Утар авылы, Ленин урамы, 4 нче йорт, Кызыл Утар авыл клубы залы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2022 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Яңа Өҗем торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Яңа Өҗем торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы

студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Яңа Өҗем авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урамга яктырткычлар сатып алу;
3) зират өчен бензин триммеры сатып алу.

"РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кызыл Утар авылы, Ленин урамы 4 нче йорт адресы буенча авыл клубы бинасындагы стендка урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: А.Х.Кашшапов